КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 16 апрель г.Казань № 422

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Һөнәре буенча иң яхшы» бөтенроссия һөнәри осталык конкурсының төбәк этапларын Татарстан Республикасында уздыру турында» 2025 ел, 27 июнь, 470 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Һөнәре буенча иң яхшы» бөтенроссия һөнәри осталык конкурсының төбәк этапларын Татарстан Республикасында уздыру турында» 2025 ел, 27 июнь, 470 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2026 ел, 23 гыйнвар, 34 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган «Һөнәре буенча иң яхшы» бөтенроссия һөнәри осталык конкурсының төбәк этапларын Татарстан Республикасында уздыруны әзерләүне һәм уздыруны оештыру комитеты составында:

оештыру комитеты составыннан А.М.Пахомовны чыгарырга;

оештыру комитеты составына Рассман Игорь Олеговичны, Татарстан Республикасы предприятиеләре һәм сәнәгатьчеләре ассоциациясе (эш бирүчеләрнең төбәк берләшмәсе) генераль директоры вазыйфаларын башкаручыны кертергә (килешү буенча);

әлеге карар белән расланган «Һөнәре буенча иң яхшы» бөтенроссия һөнәри осталык конкурсының төбәк этапларын Татарстан Республикасында оештыру буенча оештыру-техник тәэмин итү һәм координацияләү өчен җаваплы республика башкарма хакимият органнары исемлегенең «Бюджеттан тыш номинацияләр» бүлегенә түбәндәге эчтәлекле 5 пункт өстәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «5. | Химик анализ лабораториясе | Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы |

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин